**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7670**
**21.12.2018**

«Чаллыда Яңа ел-2019» бәйрәме чараларын үткәрү көнендә Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

«Чаллыда Яңа ел-2019» бәйрәме чаралары үткәрелү уңаеннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 нче карары, шәһәр Уставының 41 маддәсендәге 9 пунктның 24.1 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. 2018 елның 31 декабрендә 20:00 сәгатьтән 23:00 сәгатькә кадәр транспорт чаралары (җәмәгать транспортыннан тыш) хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә:

- Хәсән Туфан проспекты буенча ике юнәлештә дә «Энтузиастлар бульвары» җәмәгать транспорты тукталышыннан Сөембикә проспектына кадәр юл участогында;

- Сөембикә проспекты буенча ике юнәлештә дә Рәис Беляев проспектыннан Хәсән Туфан проспектына кадәр юл участогында.

2. Тәкъдим итәргә:

- Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенә чара үткәрү вакытында гражданнар иминлеген, җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәтен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә;

- «Электротранспорт» ҖЧҖгә Муса Җәлил, Сөембикә, Рәис Беляев проспектлары буенча трамвайлар хәрәкәте интервалын биш-җиде минутка кадәр кыскартырга;

- «Электротранспорт» ҖЧҖгә, «Электротранспорт» МУПка һәм «Пассажирлар йөртү» ҖЧҖгә гомуми файдаланудагы транспорт чаралары эшен 02:00 сәгатькә кадәр озайтырга.

3. Әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин